**«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Әлмәндәр авыл җирлегенең Борнаш авылында халык җыены нәтиҗәләре һәм 2021 елда үзара салым кертү турында» 2020 елның 11 ноябрендәге 3 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Әлмәндәр авыл җирлегенең Борнаш авылында гражданнар җыенының карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Әлмәндәр авыл җирлегенең Борнаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш),500 (биш йөз) сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертүгә рөхсәт итәсезме »дигән мәсьәлә буенча 2020 елның 10 ноябрендә Борнаш авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде,һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкарырга җибәрергә:

- Борнаш авылында вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту юлы белән автомобиль юлларын ремонтлау;
- Борнаш авылында каты коммуналь калдыкларны җыю буенча эшчәнлекне оештыру, калдыкларны вакытлыча җыю урыннарын чистарту, каты коммуналь калдыкларны вакытлыча туплану урыннарыннан ташу;
- Борнаш авылында су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау (шул исәптән су линияләрен салу һәм ремонтлау, су башняларын ремонтлау, чыгым материаллары сатып алу, суүтем башняларын тоту)

«ӘЙЕ» « ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 155 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 121 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 121 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәгечә карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче Әлмәндәр авыл җирлегенең Борнаш авылында халык җыенын узган дип , халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2..« Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Әлмәндәр авыл җирлегенең Борнаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлар , балачактан инвалидлар; коляскадагы инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, күп балалы гаиләләрдән тыш),2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга һәм - түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

- Борнаш авылында вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту юлы белән автомобиль юлларын ремонтлау;
- Борнаш авылында каты коммуналь калдыкларны җыю буенча эшчәнлекне оештыру, калдыкларны вакытлыча җыю урыннарын чистарту, каты коммуналь калдыкларны вакытлыча туплану урыннарыннан ташу;
- су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау (шул исәптән, су линияләрен салу һәм ремонтлау, су башняларын ремонтлау, чыгым материаллары сатып алу, суүтем башняларын тоту)».

3. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Әлмәндәр авыл җирлегенең Борнаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә (көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, балачактан инвалидлар; коляскалы инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, күп балалы гаиләләрдән тыш) 2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзсалым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Борнаш авылында вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту юлы белән автомобиль юлларын ремонтлау;
- Борнаш авылында каты коммуналь калдыкларны җыю буенча эшчәнлекне оештыру, калдыкларны вакытлыча җыю урыннарын чистарту, каты коммуналь калдыкларны вакытлыча туплану урыннарыннан ташу;
- Борнаш авылы урамнарын яктырту (урамнарны яктырту, светодиод лампалар, чыгым материаллары сатып алу);
- Борнаш авылының су башняларына хезмәт күрсәтү һәм аларны карап тоту чыгымнарын түләү"»

4. Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

**Әлмәндәр авыл җирлеге Башлыгы** **Р. Х. Җәләлиев**